КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 1 июль г.Казань № 482

2023 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 2024 елда бер тапкыр бирелә торган түләү турында

Мәгариф лидерларына ярдәм күрсәтү, алдынгы идарә итү һәм педагогик тәҗрибәне тарату, белем бирү сыйфатын яхшырту һәм Татарстан Республикасы педагогик хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 2024 елда 30,0 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган түләү) билгеләргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

укытучылары аларга Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен премияләр түләнә торган башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары укытучылары исемлеген раслау турында» 2023 елның 11 августындагы 604 номерлы боерыгы белән расланган педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен премияләр түләнә торган башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары укытучылары исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә бер тапкыр түләү;

бу карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы өчен әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә 2023 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 2024 елда бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибен эшләргә һәм расларга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 2023 елда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2023 ел, 30 май, 659 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин